| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның 12 ноябре № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары (25.11.2024 №1049 редакциясендә)белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 29 ноябрендә 08 сәгать 30 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, сроклы хәрби хезмәт узучы гражданнардан, МХОда катнашучылардан тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Түбән Чыршылы авылы Калмык ур., Тегермән ур., Мокрый куст ур., Күл ур., Плетеная ур., Совет ур., Тукай ур., Үзәк ур.);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Чыршылы авылында Калмык ур., Тегермән ур., Мокрый куст ур., Күл ур., Плетеная ур., Совет ур., Тукай ур. буенча юлларны кардан чистарту);

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Түбән Чыршылы авылында каптажны (чишмәне) ремонтлау))

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 105 йорт буенча административ бинада, Совет урамы, 8 йорт буенча балалар бакчасы бинасында, Мельничная урамы, 23 йорт, ФАП бинасында, Югары Чыршылы авылы ,Горная урамы, 27 йорт, Мордовская Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылыавыл җирлеге» Н.Я.Хәйруллина